# Себер белән Казан арасы...

Мин бу юлы Себергә “Мәскәү-Барнаул” поезды белән барырга чыктым һәм юлыбыз якташым, журналист Наил Алан белән бергә туры килде. Ул миннән Төмәндә үтәчәк кичә өчен “Себер белән Казан арасы” дип аталган шигырь язуымны үтенде, алдыма ак кәгазь һәм каләм куеп, купемнан чыгып китте. Әлбәттә, минем заказ белән шигырь язганым юк иде, әмма концертны башлап җибәрү өчен милли хисле әсәр кирәк булгач, мин тәвәккәлләргә булдым. Тәүге ак кар яткан кыр-далалар, юлыбызга кыя булып баскан Урал таулары, шаулап каршы алган Себер урманнары, шигырь юллары булып, ак кәгазьгә төшә башладылар...

Себер белән Казан арасы,
Ике арада – Татар даласы,
Карурманнар, Урал таулары,
Тарих сагындагы ханнары,
Дөньяны тетрәткән даннары –
Себер белән Казан арасы...

Соңгы вакытта Себер тарихын җентекләп өйрәнгән, бу хакта дистәләгән фәнни-популяр мәкалә һәм “Күчем хан” дип аталган тарихи роман язган кеше буларак, мин бу тарихның никадәр бөеклеген белә идем. Татарларның Ана Ватаны булган Себер Иле, бөтен төрки кавемнәрнең нигез теле булган себер татарлары теле, бүгенге көндә дә милли үзенчәлекләрен, гайрәт һәм ихласлыкларын саклап калган себер татарлары миңа бик якын һәм газиз иде... Дәүләтен Россия империясе басып алуыннан саклап, егерме ел буе кулына кылыч тотып сугышкан 80 яшьлек, сукырайган Күчем хан минем өчен милли каһарман, Себер туфрагында туган, бөтен дөньяга ислам нурын, мәгърифәт тараткан Габдрәшит Ибраһимов минем өчен иң бөек татар иде...

Себер белән Казан арасы,
Ике арада – Татар баласы,
Дастаннарга лаек язмышы;
Иделкәе, Тубыл-Иртышы,
Ямьле җәе, салкын ак кышы,
Себер белән Казан арасы...

Әйе, бу юлларда, бу арада бөек татар тарихы җәйрәп ята, ак кар астында борынгы скиф курганнары, таш кала калдыклары йоклый, Татар бугазыннан Каф тауларына хәтле булган Татар Иле мәңгелек туңлыкта үз вакыты җиткәнне көтә, милләтнең уянуын көтә иде...

Себер белән Казан арасы,
Астаналы асыл каласы,
Мең еллык Казаны, Искәре,
Дәүләт тоткан бөек үткәне,
Бу көндә дә гомер иткәне –
Себер белән Казан арасы,

Киләчәккә шулай барасы,
Мәңгелеккә бергә каласы!

Юлда, Себер белән Казан арасында менә шушы шигырь туды, ул Төмәндә үткән конференциядә дә, концертта да яңгырады, аны кулдан-кулга күчереп тә алдылар, халыкка үз тарихын аңлаткан, рухын күтәрерлек мондый әсәрләр дә кирәктер, мөгаен. Әмма бүген минем төп сүзем ул шигырь турында түгел, ә әсәргә кермәгән, шигырь юллары арасында әйтелмичә калган борчылулар турында булыр. Себер белән Казан арасында тулып яткан проблемалар, татар тормышында хәл ителмәгән мәсьәләләр, бүгенге килеп туган шартларда милләт буларак исән калу юлларын эзләү – мине беренче чиратта менә шушы нәрсәләр борчый иде...

Себер минем өчен Котыптан – Татар далаларынача, Урал тауларыннан - Тын океангача бөек төрки-татар дәүләтләрен тоткан борынгы Туран Иле, Төрки каганатлар һәм Себер ханлыгы ул. Шуңа күрә минем Себергә мөнәсәбәтем дә башкача, ул минем өчен гадәти бер татар түбәге генә түгел, ә милләт барлыкка килгән Төп Йорт. Шуңа күрә мин Себердән, себер татарларыннан күбрәк көтәм, андагы һәр җиңү минем өчен дәүләти җиңү кебек, һәр югалту – дәүләти югалту, тарих алдында зур гаеп кебек кабул ителә. Ә соңгы вакытта Себердә югалтулар шактый шул, Казан, Урал аръягында яшәүче татар халкы аларның күбесен белмичә дә кала... Дастаннарда әйтелгәнчә:

Әүәл башлап ни бетте?
Көн бетте дә ай бетте.
Икенчеләй ни бетте?
Тау бетте дә таш бетте.
Иң соңыннан ни бетте?
Ир бетте дә ил бетте...

Татар ирләре кулыннан шаулап дәүләтләр киткәннән соң, милләт үзенең иң фаҗигале чорына килеп керде һәм бу авырлыклар әле бүген дә дәвам итә. Дөрес, эчке мөмкинлекләре гаять зур булган татар халкы Казан алынгач та, Себер ханлыгы җимерелгәч тә үзенең яшәвен дәвам итә, әмма нинди яшәү була ул? Һәр көне, һәр сәгате тел, дин, җан һәм мал өчен көрәшеп, черәшеп яшәү, газаплы яшәү була ул. Табигатьләре белән беркатлырак, ихлас күңелле, сабыр себер татарлары дәүләтсез хәлдә, басып алган милләткә буйсынып яшәүнең бөтен ачысын һәм югалтуларын үз башларыннан кичерәләр. Шушы 400 еллык коллык чорында басып алынган күп кенә төньяк халыклары инде юкка чыга, күршедәге ханты-мансылар, шор-телеутлар бармак белән генә санарлык кала, татарлардан кала, барлык җирле халыклар христиан динен кабул итәргә мәҗбүр булалар, телләрен, тарихларын югалталар. Инде шушы куркыныч себер татарларына да яный кебек...

**Чөнки Себердә татар мәктәпләре бетә, инде бетте дисәң дә була...**

Ә мәктәбе юк халыкның теле дә бетә, теле булмаса, милләт үзе дә юкка чыга...

Узган гасыр уртасында Төмән өлкәсендә 160 мәктәптә татарча укытсалар, бүгенгесе көндә нибары 59 мәктәптә татар теле атнага 1-2 сәгать предмет буларак кереп килгән, милли-региональ компонент закон нигезендә бетерелгәч, инде бу предмет та калмаячак. “В области за последние шесть лет закрыты все национальные образовательные учреждения, в которых школьные предметы преподавались на родном для сибирских татар языке”, - дип яза бу хакта “Российская газета” үзенең 2007 ел, 18 май санында. Бу язмадан күренгәнчә, Төмән өлкәсендә яшәүче татар балаларының 70 проценты үз ана телләрендә дәрес алмый икән, халыкара стандартлар буенча, төбәктә яшәүчеләрнең 30 процентган артыгы үз ана телендә белем алмаса, ул тел юкка чыга. Бүгенге көндә

Төмән өлкәсендә 250575 татар яши, шулардан бары тик 4206 бала гына татар телен предмет буларак өйрәнә ала. Хәзергә...

Төмән өлкәсендә соңгы елларда татар ата-аналары һәм балалар өстендә тәҗрибә уздырдылар – татар авылларында гөрләп эшләп торган мәктәпләрне ябып, балаларны тирә-яктагы урыс авылларына ташый башладылар, аларны милли мохиттән аерып, бары тик урысча гына укыта башладылар. Бу хәлне бигрәк тә Яркәү, Тубыл районнарында күзәтергә була, урыс мәктәпләренә йөреп укучы балаларның 75 проценты татарлар булса да, аларга татар теле укытылмый. Өлкә администрациясендә гадәттә моны ата-аналар теләгенә сылтап калдырырга яраталар, әмма бу дөреслеккә туры килми. 2006 елда Тубыл шәһәрендә урнашкан “Наследие” иҗтимагый оешмасы уздырган сорашу-опрослардан күренгәнчә, Вагай һәм Тубыл районында яшәүче татар ата-анларының 95 проценты балаларының татарча укуларын теләгән, әмма аларның теләгенә колак салучы булмаган. Нәтиҗәдә, узган ел Төмән өлкәсе мәктәпләренң бер генә татар теле укытучысы да таләп ителмәгән, шул ук вакытта рус, чит тел укытучылары йөзәрләп, хәтта меңәрләп кирәк. Шуның нәтиҗәсе буларак, Тубыл дәүләт педагогия институтының татар теле бүлеген тәмамлап чыгучылар белгечлекләре буенча эшкә урнаша алмыйлар, моны күреп, татар теле бүлегенә укырга килүчеләр кими, киләчәктә ул бөтенләй ябылырга да мөмкин.

Күрәсез, узган гасырның 90нчы еллар башында гөрләп эшләп киткән мәктәпләребез, югары уку йортларында ачылган татар теле бүлекләре, төбәкләрдәге милли матбугат, радио һәм телевидение, иҗтимагый оешмалар бүгенгесе көнне ябылу хәлендә яки инде күп урында ябылганнар. Бу – Россиядә алып барган милли сәясәтнең ачы нәтиҗәсе, урыс булмаган халыкларның, беренче чиратта – татарларның телен һәм милли мәгърифәтне юкка чыгару өчен астыртын һәм ачыктан-ачык эшләнгән корткычлык. Нишләргә? Татар байлары бик тырыша торгач, бәлки Төмәндә бер татар гимназиясе ачып та куярлар, әмма Россия мәктәпләрендә милли-региональ компонент бетерелгәч, бу гимназияләрдә татар теле факультатив кына булып калачак бит! Ягъни, бу татар гимназиясендә барлык фәннәр урысча укытыла, ә дәрестән тыш берничә сәгать татарча укый аласың, әмма бу мәҗбүри түгел һәм билге аттестатка куелмаячак. Ә урыс авылларына күчерелгән татар балалары өчен монысы да булмаячак. Күрәсез Россия татарны юк итәргә чынлап тотынды, һәм бу мәктәпләр мисалында бик ачык күренә.

Себердә татарларга карата социаль гаделсезлекнең дә бик көчле булуын әйтергә кирәк, бу бигрәк тә авылларда ачык күренә. Халыкның әйтүе буенча, татар авылларына юллар салынмый, газ кертелми, мәктәпләр ябыла, клублар эшләми, фермалар беткән, ташламалы кредит һәм субсидия бирелми, ә шул ук вакытта янәшәдәге урыс авылларында боларның барысы да бар. Нәтиҗәдә татарлар эш эзләп, балаларын укыту өчен шул урыс авылларына күчәргә мәҗбүрләр. Мәсәлђн, өлкә татарларының яртысы яшәгән Вагай, Яркәњ, Тубыл районнарында 35 эре хуҗалыктан нибары сигезе генә калган, Вагай районында бары тик Желнинскийда гына эш табарга мөмкин. Заманында 1,5 миллион баш сарык тоткан Төмән өлкәсендә, татарлар белән бергә, бу тармак үлеп бара, урыс авыллары исә дуңгызчылык белән көн күрә.

Бу якларда татарларның бер өлеше сазлы-күлле урыннарда яшәгәнлеген дә әйтеп үтәргә кирәк. Әйтик, өлкәнең Вагай, Тубыл, Түбән Тавды, Яркәү, Уват районнарында, сазлык эчендә 8 мең кеше яши, шуларның 95 проценты – татарлар. Бу сазлыклар 2 миллион 370 мең гектар җирне биләп тора, бирәдә мең гектарга нибары 3 кеше туры килә. Тарихчыларның әйтүе буенча, Себерне урыслар басып алганнан соң, чукындырудан качып, татарлар шушы сазлыклар арасына барып кергәннәр һәм мәңгегә шунда калганнар, анда кешеләр яшәгәнлеген революциядән соң гына белгәннәр, диләр. Хәзер менә шул 19 татар авылында даими электречество юк, ут дизель белән, берничә сәгатькә генә бирелә, күп авылларда эчәргә чиста су юк, халык елга бозын эретеп

эчәргә мәҗбүр, җәй көне исә ул аны салам астында саклый. Бу авылларга җәен – вертолет белән, кышын чана юлы белән генә керергә мөмкин, куркыныч юлдан даими автобус рейслары юк. Күп авылларда кадрлар кытлыгы – укытучылар юк, врачлар юк, Европа илләре хәтле биләмәләрдә нибары 20 санитар эшли, шулай итеп, бер медикка 400 кеше туры килә.

Сазлы җирдә иген үстереп булмаганга, халыкның төп һөнәре – балыкчылык, чөнки биредә елга-күлләр күп, шулай ук күпләр мүк җиләге, гөмбә, башка шуның ишеләрне җыю белән дә шөгыльләнә. Әмма балык тоту да бик нык кимегән, төрле сәбәпләр аркасында, яртылашка гына калган. Элек хөкүмәт тоткан балыкның яртысына субсидия бирсә, хәзер ул бик нык кимегән, балык әртилләренә ташламалы кредитлар бирелми, күбесе лицензияләр ала алмый. Нәтиҗәдә, балыкчылыктан башка бернинди кереме булмаган саз ягы татарлары гаять дәрәҗәдә хәерчелеккә төшкәннәр, тормыштан өметләре өзелеп бара, шул сәбәпле үз-үзләренә кул салу, эчкечелек очраклары да арткannan-арта бара. Дөрес, Төмән өлкәсе хөкүмәте бу саз ягы авыллары буенча төрле программалар кабул итә, әмма мәсьәлә нигездә хәл ителми – яшәү шартлары яхшырмый, халык эш белән тәэмин ителмәгән, милләтнең бер өлеше сазга батып бара. Шуның өстенә, Уват сазлыкларына вертолетлардан ниндидер бочкалар ташлаганнарын да әйттеләр, бу хәлләрдән соң халык рактан кырыла башлаган, сазга батырылган бочкаларда радиоактив калдыклар булырга мөмкин, диләр...

Себердәге татар авылларында әхлакның шактый какшавын да әйтеп үтәргә кирәк, бу бигрәк тә эчкечелек белән бәйләнгән. Күп авылларда ирләр дә эчә, хатын-кызлар да кимен куймый, хәтта балалар да хәмергә үрелә, диделәр. Быел саз ягындагы Лайтамак авылында 14 яшьлек ир бала асылынып үлә, эчкечелеккә сабышкан ата-анасы бу хәлне белмичә дә кала, малай өч көн чормада асылынып тора. Балага җеназа укып күмәргә мулла бабай үзе дә исерек була, карчык кеше җеназа укырга мәҗбүр була... Югыйсә бу авыл борынгы сәед-шәехләрне күргән һәм күмгән, галимнәребез тарафыннан "Сәйфелмүлек", "Бүри хан", "Алпамша", "Йиртүшлек" дастаннары язып алынган данлыклы Лайтамак авылы бит! Шунысын да әйтергә кирәк, саз ягындагы кайбер татар авылларында мәчеткә йөрергә, женаза укырга аек ир-атлар юк, боларның барысын да хатын-кызлар башкара...

Заманында ислам динен сәед һәм шәехләрнең үзләреннән кабул иткән, көчләп чукындырганда да сазлыкларга качып, мөселман-татар булып калган милләттәшләребезгә ни булды соң? Ни өчен бүген ислам дине – аларны, алар ислам динен сакламый? Дөресен әйтергә кирәк, бүгенге көндә ислам дине Себердә, бигрәк тә, татар авылларында зур каршылыклар эчендә яши. Ислам гыйлеме булмаган, йөз елга якын хак диннән аерылып торган татарларда яңадан мәҗүси гадәтләр күренә башлаган, биредә һаман курчакларга табынучылар барлыгын, урман ияләре, йорт ияләрен зурлаучылар яшәгәнлеген әйттеләр. Себер татарларының дин тотуында тагы бер бәхәсле нәрсә бар, ул да булса – астаналар мәсьәләсе. Астана дип биредә изгеләр күмелгән урыннарны әйтәләр, алар Себердә дистәләгән. Бер караганда, тарихи урын буларак, астаналарны белү, аларны карап-саклап тору гаеп эш түгел кебек, икенче караганда, бөтен динне каберләр белән генә бәйләү сәер тойгы калдыра. Кайбер урыннарда астана культы шундый зур урын алган, алар янына бару хаҗ кылу белән бәрәбәр куела башлаган. Җитмәсә, Ярков, Белич кебек урыс тарихчылары астана культын себер татарларының аерым дине, дип фәнни хезмәтләр бастырып чыгарганнар, алар халыкны саф исламнан аерып алып, каберләр тирәсендә кайнашучы мистиклар итеп кенә калдырырга телиләр. Моңа каршы чыккан белемле татар егетләрен, дин әһелләрен "ваххабитлар" дип төрмәләргә утырта башлаганнар, нәтиҗәдә, мөселманнар берничә төркемгә бүленгән, мөфтиятләр, казыятлар да берничә һәм төрле-төрле. Миңа калса, халык чытырдап ябышкан ул астаналарга, шәҗәрәләргә тарих итеп, фән

күзлегеннән карарга һәм бәя бирергә кирәк, ә хак динне тоту өчен, гыйлем кирәк, ягъни, өч-дүрт авылга бер булса да мәдрәсә ачып, халыкка ислам белеме бирергә кирәк. Милләтебез Аллаһ кушканча яши башласа, Себер Иленң дә бәрәкәт килер, иншаллаһ!

Әйткәнемчә, мин Себерне башка төбәкләрдән югарырак күрергә телим һәм аннан күбрәк көтәм, чөнки ул заманында зур дәүләтләр тоткан тарихи традицияле җир. Әмма бүгенгесе көндә Себердә күп нәрсә үзешчәнлек дәрәҗәсендә әле, бу сәнгатькә дә, әдәбиятка да, тарихка да кагыла. Дөрес, Тубыл һәм Төмән институтларында татар теле бүлекләре бар, себер татарларының үз профессорлары, галимнәре күренә башлады, әмма алар – диңгездәге тамчы гына. Үзенең галимнәре, укытучылары, милли кадрлары белән заманында Себерне Казан күтәргән, хәзер ул элементәләр дә өзелеп бара, 2-3 мең хезмәт хакы өчен беркем үз теләге белән Себергә чыгып китми. Димәк, милли кадрларны Себернең үзендә әзерләргә кирәк, Казанга укырга да яшьләрне яңадан Себергә кайту максаты белән җибәрергә кирәк. Шулай ук Төмәндә яки Тубылда Казандагы тарих институтының филиалын ачар вакыт та җитте, мондый бүлекчәләр Саратов һәм Ульяновский шәһәрләрендә эшләп килә бит инде! Себер тарихы буенча махсус фильмнар, телевизион тапшырулар эшләр вакыт та җитте, шулай ук Себердән чыккан милли каһарманнарны, атаклы кешеләрне дә яңадан милләткә танытырга, кайтарырга кирәк, дип уйлыйм, бу милләтнең рухын күтәрергә ярдәм итәр иде!

Шунысы куандыра, соңгы вакытта Себердә, бигрәк тә Төмән белән Тубылда татар милли хәрәкәте тагы көчәя башлады, хәрәкәткә яңа көчләр килеп кушылды, яңа идеяләр туды, өр-яңа гамәлләр күренә башлады. Мин моңа бик сөенәм, чөнки бу хәл милләтнең эчке мөмкинлекләре зур булуын күрсәтә, нинди шартларда да татарлар исән калу өчен тырыша, ул гына да түгел, күтәрелү, үсү юлларын эзли. Мин моның шулай икәнлеген соңгы елларда Себергә баруларымда да күрдем, татар хәрәкәтенә килеп кушылган яңа кешеләр белән аралаштым, алардан ташып торган энергияне сизеп, сөендем, эш-гамәлләренә фатихамны бирдем.

Бу урында мин 2 ел элек Тубылда эшләп киткән "Наследие" иҗтимагый хәрәкәтенә, аның яшь һәм көчле лидеры Луиза Шәмсетдиновага, Төмәндә оешкан татар конгрессына һәм аның эшлекле лидерларына аерым тукталасым килә. Луиза ханым шушы кыска вакыт эчендә Себер ханлыгының элеккеге башкаласы булган Искәрне торгызу буенча күп эшләр башкарды, анда мәчет һәм музей салдырырга җир алуга иреште, Искәрне туристик маршрутка кертте, себер татарлары проблемалары буенча берничә зур фәнни конференция һәм милли чаралар үткәрде. Төмән өлкәсе татарлары конгрессы исә кыска вакыт эчендә күп кенә татар милли оешмаларын үз тирәсенә туплый алды, үзенең "Искәр" дип аталган нәшриятын ачып җибђәрде, Себер тарихына караган китаплар чыгарды, инде альманах чыгарырга җыеналар, "Сибирия – Себер Иле" дип аталган газетасын чыгара башлады, үз сайтларын ачты, Казанда үткән "Алтын мөнбәр" кино фестиваленең төп спонсорларының берсе булды, күп кенә милли чаралар, конференцияләр уздырды.

Шушы көннәрдә Төмәндә үткән татар иҗтимагый оешмаларының конференциясен дә өлкәнең татар конгрессы уздырды, югарыда телгә алган проблемалар барысы да диярлек анда күтәрелде, бу хәлләрдән чыгу юллары эзләнде. Мин ышанам, Күчем хан кебек гайрәтле милли лидерлар –Нурулла Саттаров, Ринат Насыйровлар, Себер ханбикәсе Сүзге кебек гүзәл һәм кыю Луизалар булганда, милләт әле яшәр, сазлыктан чыгу юлларын табар, яңадан үзенең алтын тәхетенә утырыр, иншаллаһ! Без исә аларга кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез, авыр чакта, җилкәбезне куярбыз, шатлык килгәндә, бергәләп бәйрәм итәрбез, Төп Йортыбыз – Себер Илен бергәләп саклап калырбыз, иншаллаһ!

Себер белән Казан арасы,

Ике арада – Татар баласы,
Мәңгелеккә шулай каласы,
Киләчәккә бергә барасы –
Себер белән Казан арасы...

**Фәүзия Бәйрәмова,**
*язучы, тарих фәннәре кандидаты,*
*Бөтендөнья татар конрессының башкарма комитеты әгъзасы.*
2007 ел, 18 ноябрь.